ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛОКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.З.Закирова, д.47, с. Малые Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422172

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КЕЧЕ КИРМӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
З.Закиров ур., 47 нче йорт, Кече Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422172

тел.(факс): (85563) 2-96-17; e-mail: MKir.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар Постановление

№ 24 22 декабрь 2017 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 сентябрендәге 681 номерлы карары белән расланган «Яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләренең 8 пункты, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Кече Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Әлеге карарга кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге территориясендә көнкүрештә кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеген расларга.

2. Эшкәртелгән терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге турында мәгълүматны урнаштыру түбәндәгечә башкарыла дип билгеләргә:

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлегенең түбәндәге адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында:

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Кече Кирмән авылы, З.Закиров урамы, 47 йорт;

2. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы Норма авылы, Көнчыгыш урамы, 19 А йорт;

3. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Югары Яке авылы, Үзәк урам, 19 йорт,;

4. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Су-Елга авылы, Тынычлык урамы, 13 йорт;

5. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Норма урман хуҗалыгы поселыгы, Урман урамы, 12 Б йорт;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук кулланылган һәм яраксызга әйләнгән тererekөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарында урнаштырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе /Г.М.Асҡаров/

Приложение
к постановлению
Исполнительного комитета
Малокирменского сельского
поселения Мамадышского
муниципального района
Республики Татарстан
от 22.12. 2017 г. № 24

**Перечень**
**мест первичного сбора и размещения отработанных ртутьсодержащих ламп у потребителей ртутьсодержащих ламп на территории Малокирменского сельского поселения Мамадышского муниципального района Республики Татарстан**

| № | Адрес места **первичного сбора и размещения отработанных ртутьсодержащих ламп** |
|---|---|
| 1. | 422172, Республика Татарстан, Мамадышский район, с. Малые Кирмени, ул. Г.Нигматуллина (здание старый медпункт). |